РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, РТ БазарлыМатакавылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

# КАРАР
# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

2019 елның 31 нче гыйнваре 23№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы "Җирләү һәм җирләү эше турында" Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы ««Татарстан Республикасында Күмү һәм җирләү эше турында "Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.2018 елның 1 февраленнән Әлки муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 5946,47сум дип билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 31 гыйнварында кабул ителгән 39а номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында» карарын 2019 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең территориаль үсеш буенча урынбасары Нуруллин Э. Г. йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе Йосыпов И.В.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе
карарына
1 нче кушымт
2019 елның 31 гыйнвары 23№

Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районында 2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исемлеге** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.Табут һәм җирләү өчен башка кирәк – яракларны бирү, китерү | 2 253,61 |
| 3. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1 183,15 |
| 4.Күмү( кабер казу һәм күмү) | 2 509,71 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе
карарына
2 нче кушымта

2019 елның 31 гыйнвары 23№

Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районында 2019 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исемлеге** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.Киендерү (төрү) | 265,49 |
| 3.Табут һәм җирләү өчен башка кирәк – яракларны бирү, китерү | 2 253,61 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1 183,15 |
| 5.Күмү( кабер казу һәм күмү) | 2 244,22 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |